КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 март г.Казань № 166

2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен (алга таба – Дәүләт йөкләмәсе);

Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төбәк төрләре буенча тиешле эшчәнлек өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне минимальләштерүдә чагылдырылган «А» төркеменә керә торган контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары гамәлгә ашыра торган контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволарның хисаплары» бердәм дәүләт хисап системасында (алга таба – Система) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының хисап формаларына Дәүләт йөкләмәсе нигезендә үзгәрешләр кер-

тергә;

хисап елына индикаторларның чик күрсәткечләрен кертүне, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына беркетелгән Системадагы күрсәткечләрнең факттагы мәгънәләрен актуаль хәлдә тотуны тәэмин итәргә;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр, һәм 30 гыйнварга кадәр – IV квартал индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан квартал күрсәткечләрен үтәү мониторингы нигезендә һәр квартал күрсәтечләренә ирешү йомгаклары турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

ел саен, 1 апрельгә кадәр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында алга таба карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан узган ел өчен Дәүләт йөкләмәсен үтәү мониторингы нигезендә аны үтәү йомгаклары турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә:

Дәүләт йөкләмәсе индикаторларының факттагы күрсәткечләрен Системага кертүне һәм хисапларны анда бастыруны тәэмин итәргә:

һәр квартал индикаторлары буенча – хисап кварталыннан соң килә торган айның 18 енә кадәр һәм IV квартал индикаторлары буенча – 25 гыйнварга кадәр;

еллык индикаторлар буенча – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган сроклар нигезендә;

агымдагы елның 1 декабренә кадәр планлаштырылган өч елга Дәүләт йөкләмәсен формалаштыру максатларында теркәлгән индикаторлар буенча агымдагы ел мәгънәләрен һәм өч елга планлаштырыла торган иң чик мәгънәләрен бәяләүне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары өчен индикаторны исәпләүче һәм Системага мәгънәләр кертүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына хисап кварталыннан соң килә торган айның 16 сына кадәр һәм IV квартал индикаторлары буенча – 23 гыйнварга кадәр Системага Дәүләт йөкләмәсенең һәр квартал индикаторларының факттагы күрсәткечләрен кертүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә Системадагы мәгълүматларны регламент срогы үткәннән соң актуальләштерергә кирәк булганда бу хакта Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына хәбәр итәргә.

6. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) функцияләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү тәртибендә билгеләнгән таләпләргә таянып эш итәргә.

7. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

индикаторларның үтәлешен бәяләү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, эшчәнлек нәтиҗәлелеге индикаторларының иң яхшы мәгънәләренә ирешүне бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләрен стимуллаштыру турында карар кабул итәргә хокуклы;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең Дәүләт йөкләмәсен үтәү процентын санау максатларында алар тарафыннан барлык индикаторлар мәгънәләренә ирешү буенча һәр квартал рейтингын формалаштырганда индикаторларның авырлыгы тигез дип санала;

еллык күрсәткечләрнең факттагы мәгънәләре хисап чорыннан соң килә торган II квартал мәгълүматларын бәяләгәндә исәпкә алына;

хисап чорында мәгълүматы булмаган квартал күрсәткечләренең факттагы мәгънәләре киләсе кварталда мәгълүматларны бәяләгәндә исәпкә алына;

хисапны бастырып чыгару датасына Дәүләт йөкләмәсе индикаторлары буенча статистик мәгълүматлар булмаган очракта, хисап формасына киләсе хисап чорында факттагы мәгънәләрне кертеп, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органын бәяләү буенча мәгълүматлар кертелә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына бер ай эчендә дәүләт программаларына аларның индикаторлары мәгънәләрен Дәүләт йөкләмәсе индикаторлары мәгънәләренә туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

9. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2020 ел, 21 февраль, 125 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2020 ел, 21 февраль, 125 нче карары белән расланган 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 март, 215 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2020 ел, 21 февраль, 125 нче карарына

үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 26 июнь, 532 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 октябрь, 916 нчы карарының 2 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 декабрь, 1218 нче карарының 2 пункты.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин